Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

25 июль 2022 ел № 10

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 4 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 4 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

2.5. бүлеге 2.5.1 пунктындагы 5,6 пунктчаларын төшереп калдырырга;

1.2. 2.6. бүлеге 2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчаны өстәргә:

«4) индивидуаль торак йортка хокук билгели торган документлар (әгәр милек хокукы Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлмәгән булса)".

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Бишмунча авылы Совет урамы, 57А нче йорт; Кама-Елга авылы, Кама-Елга урам, 26А йорт; Ак-Чишмә авылы, Ак-Чишмә урамы, 1 нче йорт, Бахчасарай авылы, Җиләкле урамы, 1йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Бишмунча авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г.Фазлиев